**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КӘЗКӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

42361, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2 а нчыйорт.
Тел.3-44-46

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЗКЕЕВКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«13» ноябрь 2020ел** **№ 11**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең Кәзкәй һәм Тыңламас авылларында халык җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районы «Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Кәзкәй авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1) 2020 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Актаныш муниципаль районы Тыңламас торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2) 2020 елның 24 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең Кәзкәй авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда үзара салым түләүләренең бер тапкыр 18 яшькә җиткән һәр граждандан 500 (биш йөз) сум күләмендә кертелүенә, яшәү урыны, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашуларына, алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, аларның саны җирлек чикләрендә яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 процenттан артмаска тиеш - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- җирлек чикләрендә Халыкны электр белән тәэмин итү һәм электр белән тәэмин итүне оештыру

“ӘЙЕ “ " ЮК”

3. Халык җыенын түбәндәге адреслар буенча үткәрергә:

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Кәзкәй авылы, Беренче май ур., 1а;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Тыннамас авылы, Октябрь ур., 72Б йорт.

4. Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Күзкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә.

6. Үтәлешне контрольдә тотам.

Актаныш муниципаль районы

Кәзкәй авыл җирлеге Советы белән рәислек итүче Тохбатуллин Х.Х.